# Камилсез булуыңны танып яшәргә өйрән

Максималистлар тормышта хаталарга урын калдырмый диярлек; нәтиҗәдә, алар үз-үзләреннән һәм башкалардан өметләрен өзә. Сиңа максимализм хасмы? Шулай икән, биредәге киңәшләрне кулланып кара.

## 1 ПРОБЛЕМАНЫ БИЛГЕЛӘ

Аеруча максимализм билгеләре чагылган өлкәне билгелә.



○ МӘКТӘП
(Иң югары билге алмасаң, кәефең нык кырыла.)



○ ӨЙ
(Бүлмәң тәртипкә китерелгәндә әйберләрнең берсе генә булса да үз урынында тормаса, күңелсезләнәсең.)



○ ДУСЛАР
(Башкаларның, бигрәк тә якын иптәшләреңнең, хаталарына карата тамчы да түземле булмау.)



○ БАШКАЛАР

________________________________________

________________________________________

Ә хәзер билгеләп куйган өлкә турында уйлан.
Тормышыңның шул өлкәсендә максимализм ничек итеп чагыла?

________________________________________

________________________________________

________________________________________



© 2017 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

## 2 ЯҢАЧА ЭШ ИТҮ ЮЛЫН ТАП

Изге Язмаларда «югарыдан килүче зирәклек... юл бирүчән [ягъни акыллы]» дип әйтелгән (Ягъкуб 3:17). Максимализм билгеләре чагылган өлкәдә үз-үзеңә (я башкаларга) карата таләпчән булмас өчен, син ничек акыллылык күрсәтә алыр идең?

- **Максималистларча эш итәр урынына, мәсәлән:**

________________________________________

________________________________________

- **Мин болай эш итә алыр идем:**

________________________________________

________________________________________



## 3 ШИГЫРЬНЕ САЙЛА

Нинди шигырь синең өчен аеруча туры килә?

- ○ «Ул [Йәһвә]... Аллаһың юлында тыйнак йөрүеңне тели!» (Микай 6:8).
- ○ «Гөнаһларга төпченеп карасаң, и Йәһ, Алдыңда, и Йәһвә, кем тора алсын?» (Зәбур 130:3).
- ○ «Җир йөзендә гел игелек кылып яшәгән һәм бер дә гөнаһ кылмаган тәкъва кеше юк» (Вәгазьче 7:20).
- ○ «Барысы да гөнаһ кылган һәм Аллаһының данынан мәхрүм калган» (Римлыларга 3:23).
- ○ «Акыллы булуыгыз һәркемгә билгеле булсын» (Филипиялеләргә 4:5).

Сайлаган шигырь сиңа максимализм белән көрәшергә ничек ярдәм итә ала?

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________

________________________________________



© 2017 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania

# 4 ҮРНӘК МИСАЛЛАР САЙЛА

Акыллылык күрсәтү ягыннан *син* кемнән үрнәк ала алыр идең һәм ни өчен?



«Максимализм билгеләре чагылганда, мин үзләренә җәлеп итүче кешеләрне күз алдына китерәм. Алар арасында үзеңне рәхәт, иркен хис итәсең. Бу мине бик сокландыра! Аларның үрнәкләре миңа максимализмымнан арынырга көч өсти. Мин дә башкаларның минем янымда үзләрен шулай хис итүләрен телим» (Анна).



# 5 МАКСАТЛАР КУЙ

Максимализмнан арыныр өчен, син нинди максатлар куя алыр идең?

«Нәрсәдер син ниятләгәнчә бармаса, үзеңә „мин кулымнан килгәннең барысын да эшләргә тырыштым“ дип әйт. Игътибарыңны уңай якларга тупла. Һәр уңышсызлыкка берәр нәрсәгә өйрәну мөмкинлеге итеп кара» (Кара).


© 2017 Watch Tower Bible and Tract Society of Pennsylvania